**СОВЕТ БЕРЕЗКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422712, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Березка, ул. Новостройка, 15А

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАЕНЛЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422712, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Каенлык авылы, Новостройка ур., 15А

Тел./факс: +7(84365) 79-2-08, e-mail: Berez.Vsg@tatar.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**25 март 2021 г.** **№ 21**

## Инициатив проектларны гамәлгә ашыру өчен каралган Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге территориясен, территориясенең бер өлешен билгеләү Тәртибен раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, Каенлык авыл җирлеге Уставы нигезендә, Каенлык авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Инициатив проектларны гамәлгә ашыру өчен каралган Биектау муниципаль районының Каенлык авыл җирлеге территориясен, территориясенең бер өлешен билгеләү Тәртибен кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы И.И.Гатауллин

Расланган
Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге Советының
2021 елның 25 мартындагы 21 номерлы Карары белән

**Инициатив проектларны гамәлгә ашыру өчен каралган Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге территориясен, территориясенең бер өлешен билгеләү**
**Тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге тәртип инициатив проектларны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлегенең инициатив проектларны гамәлгә ашыру мөмкин булган территориясен яисә территориясенең бер өлешен (алга таба - территория) билгеләү процедурасын билгели.

1.2. Әлеге Тәртип максатлары өчен инициатив проект - Биектау муниципаль районының Каенлык авыл җирлеге Башкарма комитетына (алга таба - Башкарма комитет) кертелгән проект, аның ярдәмендә Каенлык авыл җирлегенең яки аның өлешенең халкы өчен өстенлекле әһәмияткә ия булган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне яисә аларны хәл итү хокукы Каенлык авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына (алга таба - инициативалы проект) бирелгән башка мәсьәләләрне хәл итү буенча чараларны гамәлгә ашыру тәэмин ителә;

Инициатив проектлар гамәлгә ашырыла ала торган территория Башкарма комитет карары белән билгеләнә.

1.4. Инициатив проект гамәлгә ашырылырга мөмкин булган территорияне, территория өлешен билгеләү турындагы гариза белән проект инициаторлары мөрәҗәгать итәргә хокуклы:

1) уналты яшькә җиткән һәм Каенлык авыл җирлеге территориясендә яшәүче уннан ким булмаган санда гражданнарның инициатив төркеме;

2) территориаль иҗтимагый үзидарә органнары;

3) торак милекчеләре ширкәтләре.

1.5. Инициатив проектлар гражданнарның түбәндәге яшәү территорияләре

ч к л ә р е н д ә м у н и ц

территориаль иҗтимагый үзидарә территорияләре чикләрендә;

2) торак йортлар төркемнәре;

3) торак микрорайоны;

4) авыл торак пункты;

5) гражданнарның башка яшәү территорияләре.

**Инициатив проект гамәлгә ашырылырга мөмкин булган территорияне билгеләү турында гариза кертү һәм карау тәртибе**

Инициатив проектлар гамәлгә ашырыла ала торган территорияне билгеләү өчен проект инициаторы авыл җирлеге Башкарма комитетына, аның чикләрен тасвирлап,

инициатив проектны гамәлгә ашырырга планлаштырган территорияне билгеләү турында гариза белән мөрәҗәгать итә.

Инициатив проектны гамәлгә ашыру планлаштырылган территорияне билгеләү турында гариза проект инициаторлары тарафыннан имзалана.

Проект инициаторы инициатив төркем булган очракта, гариза инициатив төркемнең барлык әгъзалары тарафыннан, фамилияләрен, исемнәрен, аталарының исемнәрен, элемтә телефоннарын күрсәтеп, имзалана.

Проектның инициаторы гаризага түбәндәге документларны куша:

1) инициатив проектның кыскача тасвирламасы;

2) инициатив төркем җыелышының инициатив проектны авыл җирлеге Башкарма комитетына кертү турында карар кабул итү һәм аны гамәлгә ашыру тәкъдим ителә торган территорияне билгеләү турындагы беркетмәсенең күчермәсен.

Авыл җирлеге башкарма комитеты гариза кергән көннән соң 15 календарь көн эчендә карар кабул итә:

1) инициатив проектны гамәлгә ашыру планлаштырыла торган территориянең чикләрен билгеләү турында;

2) инициатив проектны гамәлгә ашыру планлаштырыла торган территориянең чикләрен билгеләүдән баш тарту турында.

Инициатив проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителә торган территориянең чикләрен билгеләүдән баш тарту турындагы карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) территория Каенлык авыл җирлеге территориясеннән читкә чыга;

2) соратыла торган территория билгеләнгән тәртиптә башка кулланучыларга беркетелгән яисә милектә булса;

3) соратып алына торган территория чикләрендә башка инициатив проект гамәлгә ашырыла;

соратыла торган территориядә җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре инициатив проект максатларына туры килми;

5) соратып алына торган территориядә инициатив проектны гамәлгә ашыру федераль, йә региональ, йә муниципаль законнар нормаларына каршы килә.

Проект инициаторына кабул ителгән карар турында, кабул ителгән карарны нигезләп (кире кагылган очракта), язма рәвештә хәбәр ителә.

Әлеге Тәртипнең 2.5 пунктында күрсәтелгән очраклар билгеләнгәндә, авыл җирлеге башкарма комитеты инициатив проектны гамәлгә ашыру өчен проект инициаторларына башка территорияне тәкъдим итәргә хокуклы.

2.8. Инициатив проектны гамәлгә ашыру өчен соратып алына торган территорияне билгеләүдән баш тарту, авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан тиешле карар кабул итү өчен нигез булган каршылыкларны бетерү шарты белән, күрсәтелгән территорияне билгеләү өчен документларның кабат тапшырылуына каршылык булмый.

## Йомгаклау нигезләмәләре

Инициатив проектны гамәлгә ашыру планлаштырыла торган территорияне билгеләүдән баш тарту турында авыл җирлеге Башкарма комитетының карарына карата законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.